**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2020 Балык Бистәсе штп. № 169пи

2020 – 2025 елларга "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү" муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карарының 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торган 2020 – 2025 елларга "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү" муниципаль программасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы финанс-бюджет палатасына бюджет проектын формалаштырганда Программаны җирле бюджет акчалары исәбеннән финансланырга тиешле программалар исемлегенә кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.К. Вафина

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 26 августындагы
169 пи номерлы карары
белән расланды

**2020 – 2025 елларга “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү” муниципаль программасы**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| Программаның максатлары | Авыл территорияләрендә уңайлы тормыш шартлары булдыру, авылга һәм авылның яшәү рәвешенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | Авыл халкының үтемле (һәркем өчен мөмкин булган) һәм уңайлы торакка ихтыяҗларын тәэмин итү;<br>авылны социаль-инженерлык ягыннан төзекләндерү (уңайлылык булдыру) һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2020 – 2025 еллар |
| Елларга һәм чыганаклар буенча бүлеп программаны финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 357 002 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән федераль бюджеттан җәлеп итүгә планлаштырыла торган чаралар хисабына – 197 440 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 143 366 мең сум, муниципаль районнарның җирле бюджетлары акчалары исәбеннән – 400 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар хисабына – 15 796 мең сум.<br>Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме еллар буенча түбәндәгечә: |

| | Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджетыныкы | җәлеп итүгә планлаштырыла торган федераль бюджетныкы | Муниципаль районнарның җирле бюджетыныкы | бюджеттан тыш чыганакларныкы |
| | 2020 | 2719 | 3754 | 43 | 1835 |
| | 2021 | 17424 | 24061 | 43 | 1835 |
| | 2022 | 23847 | 32391 | 71 | 2726 |
| | 2023 | 28747 | 39698 | 71 | 2726 |
| | 2024 | 34701 | 47921 | 86 | 3337 |
| | 2025 | 35928 | 49615 | 86 | 3337 |
| | Всего | 143366 | 197440 | 400 | 15796 |
| | Татарстан Республикасы бюджетыннан программа юнәлешләре буенча бүлеп бирелә торган акчаларның суммасы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен ачыкланачак | | | | |
| Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Файдалануга кертеләчәк:<br>авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен гомуми мәйданы 1 728 кв. метр булган торак;<br>22,4 километр озынлыкта бүлү газ челтәрләре;<br>12 километр озынлыктагы локаль суүткәргечләр;<br>авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына 12 километр озынлыкта гомуми файдаланудагы автомобиль юллары | | | | |

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсе, төп проблемалар, аларның чишелешен бәяләү һәм үсеш фаразлары

Хәзерге этапта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының үсеше дәүләт тарафыннан авыл территорияләрен үстерүгә игътибар арту белән сыйфатлана.

2014 елдан башлап “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы тормышка ашырылды, ул Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы турында”гы 2013 елның 15 июлендәге 598 номерлы карары белән расланган иде. Программа буенча 11 юнәлеш буенча чаралар финансланды, шул исәптән инженерлык челтәрләре, социаль-мәдәни-көнкүреш объектлары, сәламәтлек саклау, торак һәм башкалар өлкәсендә. 2014 елдан әлеге программа кысаларында авыл җирлегендә эшләүче яшь гаиләләрне һәм яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырылды. Авыл җирендә торак йортларны (фатирларны) челтәрдән газ белән тәэмин итү дәрәҗәсе 98 процент, авыл халкын эчәргә яраклы су белән тәэмин итү дәрәҗәсе 70 процентка кадәр тәшкил итте.

Авылда яшәү шартларын яхшырту, башка факторлар белән беррәттән, аграр өлкәдә инвестицион активлыкны арттыруга, социаль хәлне яхшыртуга ярдәм итте.

Шул ук вакытта тормышка ашырылган чаралар авыл территорияләренең икътисади потенциалын тулысынча һәм нәтиҗәле файдалану һәм авыл халкының тормыш сыйфатын арттыру өчен җитәрлек түгел.

Территорияләрне тотрыклы үстерү чараларын тормышка ашыруда дәүләтнең ролен көчәйтү максатчанлыгы түбәндәгеләр белән нигезләнгән:

авыл территорияләрен тотрыклы үстерүнең максатчан куелышларының (юнәлешләренең) авылда тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, икътисадның аграр һәм башка секторларын икътисади үстерү өчен социаль нигезләр булдыру өлешендә Россиянең социаль-икътисади үсеш өстенлекләре белән үзара бәйләнеше;

авыл территорияләренең социаль проблемаларын хәл итүгә системалы якын килүне таләп итүче озак вакытка исәпләнгән характеры;

авылның проблемалы мәсьәләләрен хәл итүнең дәүләт ярдәмен җәлеп итүне таләп итә торган югары сарыф итүлек (чыгымлылык) дәрәҗәсе.

Программаның максатларына ирешү авыл территорияләрендә яшәү шартларын яхшыртуга, агросәнәгать комплексында һәм тулаем авыл икътисадында инвестицион активлыкны үстерү өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итәчәк.

Программа максатларына ирешү өчен авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә куелган бурычларны хәл итү зарурлыгын нигезләү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл җирендә хезмәт потенциалын формалаштыруга сизелерлек йогынты ясый торган уңай булмаган демографик вазгыять;

авыл территорияләрендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешнең түбән дәрәҗәсе;

авыл җирендә торак базары үсешенең һәм авыл халкы өчен торак шартларын яхшырту проблемаларын хәл итү мөмкинлегенең түбән дәрәҗәсе;

авыл җирлегенең яшәү мохите буларак җәлеп итмәүчелеге һәм миграцион (читкә китү) кәефләр үсеше, шул исәптән авыл яшьләре арасында да;

авыл халкының социаль активлыгының түбән дәрәҗәсе;

җәмгыятьтә авыл территорияләрен үстерү перспективаларына уңай караш булмау.

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясенең "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасы нигезендә эшләнде.

## II. Программаның максатлары, бурычлары һәм көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләре, аны тормышка ашыру сроклары

Авыл территорияләрендә уңайлы тормыш шартлары булдыру, авылга һәм авылның (авылдагы) яшәү рәвешенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру программаның максатлары булып тора.

Максатка ирешү өчен авыл халкының үтемле (һәркем өчен мөмкин булган) һәм уңайлы торакка ихтыяҗларын тәэмин итү, авылны социаль-инженерлык ягыннан төзекләндерү (уңайлылык булдыру) һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү бурычларын хәл итү зарур.

Булган потенциалны нәтиҗәле файдалану, дәүләт ярдәме һәм бюджеттан тыш инвестицияләрне җәлеп итү куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Куелган максатларга һәм бурычларга ирешү тәэмин итәчәк:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен гомуми мәйданы 1 728 кв. метр булган торакны, 22,4 километр озынлыкта бүлү газ челтәрләрен, 12 километр озынлыктагы локаль суүткәргечләрне, авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына 12 километр озынлыкта гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын гамәлгә кертүне.

Программаны тормышка ашыру вакыты (срогы): 2020 – 2025 еллар.

## III. Программаның төп чараларына сыйфатлама

Программа түбәндәге чараларны үз эченә ала:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту һәм торак урын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше;

авыл җирендә урнашкан торак пунктларны социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән комплекслы төзекләндерү (уңайлы итү), шул исәптән авыл территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыру, газлаштыру, авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне үстерү, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып баручы каты өслекле автомобиль юллары челтәрен үстерү.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларының максаты – авыл халкын үтемле (һәркем өчен мөмкин булган) һәм уңайлы торак белән тәэмин итү, авыл җиренә яшь белгечләрне тарту һәм беркетү.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту мөмкинлеген арттыру түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыру күздә тотыла:

авыл территорияләрендә торак төзүгә һәм сатып алуга федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән социаль түләүләр;

наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак төзелешен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән алга таба сатып алу хокукы белән финанслашу;

торакны төзегәндә (сатып алганда) ташламалы ипотека торак кредитлавы һәм ана (гаилә) капиталы механизмнарын файдалану;

торак өлкәсендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру нигезендә авыл җирлегендә торак төзелеше күләмнәрен арттыру.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга һәм торак урын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелешенә муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирендә урнашкан торак пунктларны социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән комплекслы төзекләндерү чараларын тормышка ашыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

авыл территорияләрен төзекләндерү;

авыл территорияләрендә газлаштыруны үстерү;

авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне үстерү;

авыл территорияләрендә компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашыру;

компактлы торак төзелеше өчен авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектлары белән төзекләндерү һәм мәйданчыкларны төзекләндерү буенча проектларны тормышка ашыру;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып баручы каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү;

Авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 357 002 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән федераль бюджеттан җәлеп итүгә планлаштырыла торган чаралар хисабына – 197 440 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 143 366 мең сум, муниципаль районнарның җирле бюджетлары акчалары исәбеннән – 400 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар хисабына – 15 796 мең сум.

Программа кысаларында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү, авыл җирлегендә түбәндәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары челтәрен үстерү: бүлүче газ челтәрләре, локаль суүткәргечләр, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына илтүче каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү күздә тотыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен төп чаралардан чыгып кирәкле финанс ресурслары күләме 2 нче таблицада китерелә.

## V. Программаны тормышка ашырудагы хәтәр тәвәккәллекләрне анализлау һәм әлеге хәтәр тәвәккәллекләр белән идарә итү чараларын тасвирлау

Программаны тормышка ашыру түбәндәге төп хәтәр тәвәккәллекләр белән бәйле:

федераль законнарны үзгәртү;

программаны финанс белән тәэмин итүнең төрле чыганакларыннан финанслауның булмавы яисә тулысынча финансланмавы.

Программаны тормышка ашыруның хәтәр тәвәккәллекләре белән идарә итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясенең "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасында каралган чараларны куллану нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Таблица 1

## “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү“ программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Программаның максаты – авыл җирендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру, авылга һәм авылдагы яшәү рәвешенә уңай караш формалаштыру.

| Бурычның аталышы | Төп чараларның аталышы | Башкаручылар | Нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның кыйммәтләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Авыл халкын һәркемгә мөмкин булган һәм уңайлы торак белән тәэмин итү | Авыл территориялә рендә яшәүче гражданнар ның торак шартларын яхшырту | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (килешенү буенча) | Авыл территорияләрендә (авыл агломерацияләрендә) яшәүче гражданнар өчен торак тапшыру – барлыгы, кв. метр, шул исәптән: | 3 | 3 | 5 | 5 | 6 | 6 |
| | | | авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | 3 | 3 | 4 | 4 | 5 | 5 |
| | | | торак урын наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзелеше | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Авыл территория ләрен социаль һәм | Авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструкту расын үстерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, | Бүлү газ челтәрләрен гамәлгә кертү, км | 1 | 3 | 3,5 | 4 | 5 | 5,9 |
| | | | Локаль суүткәргечләрне гамәлгә кертү, км | - | 1 | 2 | 2,5 | 3 | 3,5 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| инженер лык ягыннан төзекләнде рү дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (килешенү буенча) | Авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып баручы автомобиль юлларын файдалануга тапшыру, км | - | 1,5 | 2 | 2,5 | 3 | 3 |
| | | | Торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектлары тормышка ашырылган авыл җирендә урнашкан торак пунктлар саны, берәмлек | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| | | | Авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм мәйданчыкларны төзекләндерү буенча компакт торак | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | төзелешенә тормышка ашырылган проектлар саны, берәмлек | | | | | | |
| | | | Авыл территорияләрен төзекләндерү буенча тормышка ашырылган проектлар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 2 | 2 | 3 |
| | | | Авыл территорияләрен яисә авыл агломерацияләрен комплекслы үстерүнең тормышка ашырылган проектлары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - |

Таблица 2

**"Авыл территорияләрен комплекслы үстерү"**
**программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

(мең сумнарда)

| Бурычның аталышы | Чараның аталышы | Финанслау чыганагы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Программа буенча барлыгы | барысы | 8351 | 43363 | 59035 | 71242 | 86045 | 88966 |
| | | федераль бюджет | 3754 | 24061 | 32391 | 39698 | 47921 | 49615 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 2719 | 17424 | 23847 | 28747 | 34701 | 35928 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | 43 | 43 | 71 | 71 | 86 | 86 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | 1835 | 1835 | 2726 | 2726 | 3337 | 3337 |
| Авыл халкын һәркемгә мөмкин булган һәм | Авыл территориялә рендә яшәүче гражданнар | федераль бюджет <*> | 2543 | 2543 | 3391 | 3391 | 4239 | 4239 |
| | | Татарстан Республикасы | 1842 | 1842 | 2456 | 2456 | 3069 | 3069 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| уңайлы торак белән тәэмин итү | ның торак шартларын яхшырту | бюджеты | | | | | | |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | 43 | 43 | 58 | 58 | 73 | 73 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | 1835 | 1835 | 2447 | 2447 | 3058 | 3058 |
| | Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше | федераль бюджет <*> | - | - | 649 | 649 | 649 | 649 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 470 | 470 | 470 | 470 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | - | - | 13 | 13 | 13 | 13 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | 279 | 279 | 279 | 279 |
| Авыл территорияләрен социаль һәм инженерлык ягыннан төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү һәм | Авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү - | федераль бюджет <*> | - | 16675 | 22233 | 27792 | 33350 | 33350 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | 12075 | 16100 | 20125 | 24150 | 24150 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| автомобиль юллары белән тәэмин итү | барысы, шул исәптән: | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | |
| | авыл территорияләрендә газлаштыруны үстерү | федераль бюджет <*> | 1211 | 3635 | 4241 | 4846 | 6058 | 7148 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 877 | 2632 | 3071 | 3509 | 4387 | 5177 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | | | | | | |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | |
| | авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне үстерү | федераль бюджет <*> | - | 1208 | 2416 | 3020 | 3624 | 4228 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | 875 | 1750 | 2187 | 2625 | 3062 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | | | | | | |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | |